ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2018 Казан ш. № 5-8/тэ

«Казэнерго» акционер җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен бирү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында

"Җылылык белән тәэмин итү турында" 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында" 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең "Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында" 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Казэнерго» Акционер җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен бирү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны әлеге карарга 1нче кушымтада каралган календарь бүленеш белән билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. 2019-2023 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулын кулланып тарифларны формалаштыру өчен, җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чорына тәгаенләнеп, озак вакытка исәпләнгән җайга салу параметрларын әлеге карарның 2нче кушымтасына нигезләнеп билгеләргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.11.2018 № 5-8/тэ номерлы карарына
1нче кушымта

# 2019-2023 елларга календарь бүленеш буенча «Казэнерго» акционер җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясе бирү хезмәтенә тарифлар

| т/б № | Муниципаль берәмлекнең, җайга салына торган оешманың исеме | Тариф төре | Ел | Җылылык чыганагы төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «Казэнерго» акционер җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар бүлеп каралмаган очракта, кулланучылар өчен | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 65,35 | - |
| | | | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 66,75 | - |
| | | | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 65,95 | - |
| | | | 2020 елның 1 июленнән алып 2020 елның 31 декабренә кадәр | 67,70 | - |
| | | | 2021 елның 1 гыйнварыннан алып 2021 елның 30 июненә кадәр | 67,00 | - |
| | | | 2021 елның 1 июленнән алып 2021 елның 31 декабренә кадәр | 68,52 | - |
| | | | 2022 елның 1 гыйнварыннан алып 2022 елның 30 июненә кадәр | 67,93 | - |
| | | | 2022 елның 1 июленнән алып 2022 елның 31 декабренә кадәр | 69,58 | - |
| | | | 2023 елның 1 гыйнварыннан алып 2023 елның 30 июненә кадәр | 69,02 | - |
| | | | 2023 елның 1 июленнән алып 2023 елның 31 декабренә кадәр | 70,50 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
16.11.2018 № 5-8/тэ номерлы карарына 2нче кушымта

2019-2023 елларга, билгеләнгән тарифларны индексацияләү ысулын кулланып тарифларны формалаштыру өчен, җайга салуның озак вакытка исәпләнгән чорына тәгаенләнеп, озак вакытка исәпләнгән җайга салупараметрлары

| т/б № | Муниципаль берәмлекнең, җайга салына торган оешманың исеме | Ел | Операцион чыгымнарның нигез дәрәҗәсе | Операцион чыгымнарның нәтиҗәлелеге индексы | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | җылылык челтәренең матди характеристикасына карата югалтулар зурлыгы | технологик югалтулар |
| | | | мең сум | % | Гкал/м$^2$ | Гкал |
| | Казан шәһәре | | | | | |
| 1 | «Казэнерго» акционер җәмгыяте | 2019 | 762,29 | 1 | 0,0 | 0,0 |
| | | 2020 | X | 1 | 0,0 | 0,0 |
| | | 2021 | X | 1 | 0,0 | 0,0 |
| | | 2022 | X | 1 | 0,0 | 0,0 |
| | | 2023 | X | 1 | 0,0 | 0,0 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге